Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының
Лагерка төп мәктәбе Гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

| « Каралды » | «Килешенде » | « Раслыйм» |
| --- | --- | --- |
| Укытучыларның МБ җитәкчесе<br>______ / Мишкина И.В./<br>__1__ нче санлы беркетмә<br>« 26 » __08__ 2021 нче ел | Директор урынбасары :<br>______ / Семенова С.Ю./<br><br>«27» __08__ 2021 нче ел | Лагерка төп мәктәбе директоры:<br>______ / Майоров А.П./<br>Боерык № ____<br>« 26 » __08__ 2021 нче ел |

**ТАТАР ТЕЛЕННӘН**

**3 нче сыйныф өчен**

**ЭШ ПРОГРАММАСЫ**

2021-2022 нче уку елы

**Төзүче: Кармышов Фаиз Минагзамович**

*Педагогик совет утырышында гамәлгә керде*

*__1__ нче санлы беркетмә*

*“__28__” __08__ 2021 нче ел*

## Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары белән гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандарты (башлангыч гомуми белем бирү - № 373, 06.10.2009 ел).
2. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында” 12138/13 номерлы (07.09.2013) хаты.
3. Урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы 1-11 сыйныфлар. Төзүче-авторлары: Р. З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2014
4. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы 1-9 нчы сыйныфлар. Төзүче авторлары: К.С. Фәтхуллова, Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Казан,2013
5. “Лагерка төп гомуми белем бирү мәктәбе”муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесенең 2021 -2022 нче уку елына календарь укыту графигы.
6. “Лагерка төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесенең 2021 -2022 нче уку елына эш программалары турындагы положениясе.

Дәреслек: Күңелле татар теле Р.З. Хәйдәрова, Г.М Әхмәтҗәнова, Л.Ә.Гыйниятуллина. Дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 3 нче сыйныф рус
балалары өчен татар теле һәм уку дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Ике кисәктә. Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2013.

## Предметның уку-укыту максатлары

Рус телле балаларга татар теле укыту максаты күпкырлы, һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

**1.Танып белү максатының эчтәлеге**: Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар исемнәрен, Татарстанның табигатен, җирлеген, топонимикасын дөрес әйтә белергә өйрәтү, аларның семантикасы белән кызыксындыру, балалар фольклоры, татар халык авыз иҗаты, әдәбият-сәнгать вәкилләре белән беренчел таныштыру башлангыч этапта танып белү максатының төп эчтәлеген тәшкил итә

**2. Үстерү максатының эчтәлеге**: балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә: фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү; хәтерне үстерү (ихтыяри, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү; аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисселек, эмпатия хисләре); ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү

**3. Тәрбияви максатның эчтәлеге**: . Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы беренче чиратта укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле, шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләре исәпкә алынды.Татар теленең грамматикасын өйрәнү процессында эчтәлектә әхлакый проблемалар булган кечкенә текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, ягъни, укучыларның эчке кызыксынуы тәэмин ителгән була. Шунлыктан тексттагы лексика, грамматика җайлырак истә кала һәм аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый

**4. Белем бирү максатының эчтәлеге:** грамматик материалның өйрәнелү тәртибе академик бирелештә түгел, аралашу хаҗәтеннән һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнә.Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Башлангыч этап өчен грамматик материал күрсәтелгән критерийларга таянып сайланды. Ягъни, укучылар нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр

## Уку-укыту предметына характеристика

Татар телен үзләштерү укучының үсешенә зур йогынты ясый. Укучы үзләштергән белемнәр алдагы сыйныфларда белем алуга нигез булып тора. 3 нче сыйныфта татар телен үзләштерү түбәндәге бүлекләрне үз эченә ала:

Белем бәйрәме
Көндәлек режим
Ашханәдә
Без эти – әниләргә булышабыз
Туган якка кыш килде
Шәһәрдә һәм авылда
Әдәпле булыйк
Кечкенә дусларыбыз
Күңелле җәй, ямьле җәй

## Уку-укыту предметының уку планындагы урыны, әһәмияте.

“Лагерка төп гомуми белем бирү мәктәбе”муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесенең 2021 -2022 нче уку елына уку планы буенча татар теленә атнага 1 сәгать бирелә, 35 атна, ел буена 35 сәгать.

Программа материалын өйрәнү барышында коммуникатив технология нигезендә эчтәлек сайлау стратегиясе һәм тактикасы түбәндәгедән гыйбарәт була: башта балаларның яшь үзенчәлегенә карап, аларның аралашү сфералары, аралашу ситуацияләре ачыклана, аннан соң ул сфераларда сөйләшүне оештыра алырлык лингвистик материалны дөрес сайлау әһәмияткә ия.

Программа материалын өйрәнү барышынды укучыларның Татарстан Республикасында яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, республиканың территориясе, географик урыны: башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары, күренекле шәхесләр турында билгеле бер мәгълүмат алуы зур әһәмияткә ия.

## Уку-укытуны үзләштерүнең шәхси предметы нәтиҗәләре

**Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре:**
Татар теленә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:
– укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни, татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;
– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, киң күңелле әңгәмәдәш булу;
– “Татар теле” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм, шулар нигезендә, белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**
Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:
– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
– “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

**Укытуның предмет нәтиҗәләре:**
Рус һәм татар телләрен өйрәнү нәтиҗәсендә, башлангыч сыйныф укучылары телнең аралашу чарасы булуына төшенәләр, аны милли мәдәни күренеш буларак кабул итәләр. Тел өйрәнү

укучы өчен белем алуның төп нигезе, аны уйларга һәм күзалларга өйрәтүдә, иҗади мөмкинлекләрен үстерүдә төп чараларның берсе булып тора. Шул ук вакытта, укучылар телдән һәм язма формада аралашу өчен, төрле мәгълүмати чараларның мөмкинлекләреннән киңрәк файдалана белергә дә өйрәнәләр. Башлангыч сыйныфларны тәмамлаганда, укучылар телдән һәм язма сөйләмнең дөреслеге кешенең гомуми культурасы дәрәҗәсен билгеләвен дә аңлыйлар. Алар туган телдәге башлангыч орфоэпик, лексик һәм грамматик төшенчәләрне, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен үзләштерәләр.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;

- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисләлек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Шәхси универсаль уку гамәлләре:**

- укучы үз халкын, туган ягын һәм туган илен ярата;
- гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге кыйммәтләрне хөрмәт итә, аларны кабул итә;
- тирә-якны актив рәвештә танып белергә омтыла;
- белем алу өчен кирәкле һәм файдалы булган эш формаларын үзләштерә;
- гаилә һәм җәмгыять алдындагы бурычларын аңлый, үзенең кылган гамәлләре өчен җавап бирергә сәләтле булуын күрсәтә;
- тирә-яктагыларга игътибарлы һәм ихтирамлы, аларны тыңлый һәм аларга үз фикерен яки мөнәсәбәтен белдерә ала;
- үзенең һәм тирә-юньдәгеләрнең сәламәт яшәү рәвеше кагыйдәләрен үтәвенә булышлык

**Предмет укытуның кыйммәте.**

Укыту- тәрбия барышында татар теле предметының кыйммәтләре:

- Татар теленә предмет буларак төшенү.
- Татар теленә өйрәтү процессы бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итү.

**Программа эчтәлеге**

| № | Бүлекләр, темалар | Эш прогр. буенча | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат |
|---|---|---|---|
| 1 | Белем бәйрәме | 4 | Беренче сентябрь – Белем бәйрәме турында сөйли, укытучыны, дустыңны бәйрәм белән котлый белү. Предметларның төсен, санын әйтеп, үзеңә сорый белү. Сумкага нәрсә салганыңны, сумкада (партада) нәрсә барлыгын, сумкадан нәрсә алганыңны әйтә, сорый белү. Үзеңнең, иптәшеңнең нинди билге алганын, диктантта нинди хата барлыгын, өй эшен эшләгәнен, эшләмәгәнен, мисал, мәсьәлә чишкәнен сорый, әйтә белү. Китапханәчедән китап сорый, китапның нәрсә турында икәнен әйтә белү. Ничә китап укыганыңны әйтә, иптәшеңнән сорый белү. |
| 2 | Көндәлек режим | 4 | Вакытны әйтә, сорый белү. Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйли белү. |
| 3 | Ашханәдә | 4 | Ашханәдә нәрсә пешергәнне, ашаганны, нинди ашлар яратканны әйтә белү. Дустыңның нинди ризыклар яратканын сорый, ашханәгә бергә барырга тәкъдим итә белү. Кунакларны каршы ала, табынга чакыра белү. Табын әзерләү тәртибен әйтә, сорый белү. Ашхәнәдә дежур укучы хезмәтен сөйли белү. |
| 4 | Без әти-әниләргә булышабыз | 4 | Әти-әниләрнең кем булып, кайда эшләвен, профессия исемнәрен әйтә белү. Өйдә үзең эшләгән эшләрне сөйли белү, иптәшеңә сорау бирә белү. Өй хезмәтендә катнашуыңны әйтә, эш куша белү. Табынны ничек әзерләү турында сөйли белү. |
| 5 | Туган якка кыш килде | 4 | Бәйрәмнең сәгать ничәдә башланганын, Яңа ел бәйрәмендә нишләгәнне әйтә белү. Һава торышын сорый, әйтә белү. Кышкы уен төрләрен әйтә, уенга чакыра белү. Чаңгы ярышы турында сөйли белү. Каникулда кайда булганыңны әйтә белү. Геройларга характеристика бирә белү. Сюжетны үзгәртеп, яңа хикәя төзи белү. |
| 6 | Шәһәрдә һәм авылда | 4 | Татарстан шәһәрләренең, елгаларының атамаларын әйтә белү.Татарстанда яшәгән милләтләрне әйтә белү. Кайсы урамда яшәгәнеңне, нинди фатирда торганыңны, мәктәпкә нинди транспортта барганыңны сөйли белү. Шәһәр турында сөйли, үзең яшәгән шәһәрне, торган йортны сурәтли белү. Шәһәргә барырга чакыра белү. Нәрсәдә барганыңны, сәгать ничәдә барганыңны әйтә белү. Авыл табигате турында сөйли белү. Җәйге уен төрләрен әйтә белү. |
| 7 | Әдәпле булыйк | 4 | Телефоннан әдәпле сөйләшә белү. Туган көнгә әдәпле чакыра белү. Килгән кунакларны каршылый белү. Туган көнгә бүләк алып килгәнне әйтә, котлый белү. Бер-береңне табынга чакыра, кыстый, ашаганнан соң рәхмәт әйтә белү. 8 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | нче Март бәйрәмендә нинди бүләкләр бирү турында сөйләшү. Өлкәннәргә урын тәкъдим итә белү. Дустыңның авыруы турында, аңа ярдәм итү турында әйтә белү. |
| 8 | Кечкенә дусларыбыз | 3 | Этләрнең кушаматын әйтә белү. Этләрне ничек караганны сөйли белү. Үзеңнең этең барлыгын, юклыгын, аны ничек караганны әйтә белү. Кешенең характер сыйфатларын әйтә белү. Песиләрнең тышкы кыяфәтен сорый, сөйли белү. Песиең барлыгын, юклыгын, аны ничек караганны сорый, әйтә белү. Кемнең нәрсә яратканын сорый һәм әйтә белү. |
| 9 | Күңелле җәй, ямьле җәй | 4 | Ел фасылларының билгеләрен әйтә белү. Җәй көне турында сөйли белү. Җәй көне укулар тәмамланганын әйтә белү. Предметларның билгеләрен чагыштырып әйтә белү. Урманга барганыңны, урманда җиләк җыйганыңны әйтә белү. Бер-береңне табынга чакыра, ашаганнан соң рәхмәт әйтә, азыкның тәмле икәнен әйтә белү. Бакчада нинди яшелчәләр үскәнен, бакчадагы эшләрне сорый, әйтә белү. Җәйге ял турында сөйли белү. Су керергә чакыра белү. Сабантуйда катнашу турында сөйләшү. |
| | Барлыгы: | 35 | |

## Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр

**Тыңлап аңлау**
Аралашу өчен, төп шартларның берсе - әңгәмәдәшләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы.
3 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:
- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда куллана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

**Диалогик сөйләм:**
Программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына җавап бирү һәм сораулар куя белү;
дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм**
Картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;
тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;
укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;
үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә мәгълүмат бирә белү.

**Уку**

Дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
тексттагы тыныш билгеләренә карап, тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү, өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонацияләре белән уку;
укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
укыганда сүзлекләр куллана белү.

**Язу**
- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;.
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен формалаштыру;
- бәйрәмнәр белән котлау язу.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**
- тиешле мәгълүматны табу һәм аерып ала белә
- төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итә белә һәм аңлый
  - иҗади һәм эзләнү төрендәге проблеманы билгели ала
  - объектларны чагыштыра, классификацияләү өчен уртак билгеләрне таба белә
  - тиешле мәгълүматны табу өчен сүзлекләр, электрон ресурслар куллана белә.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**
- уку максатын һәм бурычларын куя белә
- барлыкка килгән ситуациядә ориентлаша белә
- таныш арасыннан таныш булмаганны билгели белә
  - дәрескә кирәкле уку – язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белә;
  - дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белә һәм тәртиптә тоту күнекмәләренә ия була;

- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белә;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белә;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белә;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый һәм, кирәк булганда, төзәтмәләр кертә белә;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сыйфатларга ия булуга ирешә

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- башкаларның фикерен тыңлый, аңлый һәм аңа туры килерлек җавап бирә белә;
- парлап һәм төркемдә эшли белә;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эшчәнлектә катнаша
- үз фикеренә ышандыра белә

**Шәхси универсаль уку гамәлләре:**

- укучы үз халкын, туган ягын һәм туган илен ярата белә;
- гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге кыйммәтләрне хөрмәт итә, аларны кабул итә белә;
- тирә-якны актив рәвештә танып белергә омтыла;
- белем алу өчен кирәкле һәм файдалы булган эш формаларын үзләштерә;
- гаилә һәм җәмгыять алдындагы бурычларын аңлый, үзенең кылган гамәлләре өчен җавап бирергә сәләтле булуын күрсәтә;
- тирә-яктагыларга игътибарлы һәм ихтирамлы, аларны тыңлый һәм аларга үз фикерен яки мөнәсәбәтен белдерә ала;
- үзенең һәм тирә-юньдәгеләрнең сәламәт яшәү рәвеше кагыйдәләрен үтәвенә булышлык итә

**Граммаик минимум**

1. Исем – сүз төркеме белән таныштыру.
2. Исемнең иялек килеше белән таныштыру.
3. **Чы/-че -** исем ясагыч кушымчалары белән таныштыру.
4. Сыйфат – сүз төркеме белән таныштыру.
5. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар белән танышу.
6. Синоним һәм антоним сыйфатларны сөйләмдә куллану.
7. 21дән 100 кадәр саннарны сөйләмдә куллану.
8. **Аннан соң** рәвеше һәм **һәр, һәркем, барлык,** алмашлыклары белән таныштыру.
9. Фигыль – сүз төркеме, аның хәзерге һәм үткән заман формалары белән таныштыру.
10. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта күплектә 1,2,3 зат формалары белән таныштыру.
11. **–гына/-генә, -кына/-кенә** кисәкчәләре белән таныштыру.

12. **Янында, алдында, артында, турында** бәйлек сүзләрен сөйләмдә куллану.
13. **Ләкин, чөнки, шуңа күрә** теркәгечле җөмләләрне сөйләмдә куллану.
14. **Казан шәһәре, киемнәр кибете** – төзелмәләре белән таныштыру.
15. **Сәгать ничә? Сәгать ничәдә?** сорауларын һәм аңа җавапларны сөйләмдә куллана белү.

## Орфографик и орфоэпик минимум.

1. Өйрәнелгән лексик берәмлекләрне орфоэпия нормаларына туры китереп әйтүне ныгыту.
2. Алынма сүзләрнең дөрес әйтелешен саклап, сөйләмдә кулланырга күнектерү.
3. Укучыларның язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерү эшен дәвам итү.
4. Ике бертөрле тартык янәшә килгән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу күнекмәләрен булдыру(китте, кайтты).
5. Янәшә килгән ике бертөрле тартык булган сүзләрне икеләтеп әйтергә өйрәтү.
6. **я, ю, е** хәрефләре, алар белдергән авазларның әйтелешен һәм язылышын истә калдыруны булдыру.
7. О, ө хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы.

**Татар теленнән  контроль һәм практик эшләр.**

| Фән | Сый-ныф | Контроль эш | Мөстәкыйль эш | Күчереп язу | Сүзлек диктанты | Контроль диктант |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Татар теле | 3 | 4 | - | - | - | - |

**Календарь – тематик планлаштыру**

| № | Тема | Укучылар эшчәнлегенә характеристика яки уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план буенча | фактик үтәлеш |
| 1 | Кем? кемне? кемгә? сораулары һәм аларга җавап | Кем? кемне? кемгә? сорауларын аңлый, аларга җавап бирә белү | | |
| 2 | Кая? кайда? кайдан? сораулары һәм аларга җавап | Мәктәпкә барганны, мәктәптә укыганны, мәктәптән кайтканны әйтә белү | | |
| 3 | -мы/-ме сорау кисәкчәсе | Уку-язу әсбапларының кемгә икәнен,аларның барлыгын,юклыгын хәбәр итә белү | | |
| 4 | Мин, син, ул зат алмашлыгының юнәлеш килеш формасы | Миңа, сиңа, аңа алмашлыкларын белү һәм сөйләмдә куллану | | |
| 5 | 1 – 10 га кадәр саннар | Бердән унга кадәр төгәл,яхшы итеп саный белү | | |
| 6 | Төсләр | Предметларның төсен, санын кулланып, үзеңә сорый белү | | |
| 7 | Исем сүз төркеме | Бер-береңнең хәлен сорый белү | | |
| 8 | Исемнәрнең күплек сан кушымчасы | Исемнәргә кушымчаларны дөрес ялгый һәм күплек санда әйтә белү | | |
| 9 | Контроль эш | Укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү | | |
| 10 | Исемнәрнең 1 зат берлек санда тартым белән төрләнүе | Исемнәрне 1 зат тартым белән төрләндерә белү | | |
| 11 | Фигыльнең башлангыч формасы | Фигыльнең башлангыч формасын таба белү | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-санда төрләнеше | Хәзерге заман хикәя фигыльне зат-санда төрләндерә белү | | |
| 13 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы | Үзеңнең,иптәшеңнең нинди эшләр эшләгәнен,эшләмәгәнен әйтә белү | | |
| 14 | Үткән заман хикәя фигыльнең зат-санда төрләнеше | Үткән заман хикәя фигыльне зат-санда төрләндерә белү | | |
| 15 | Контроль эш | Укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү | | |
| 16 | Сингармонизм законы | Сингармонизм законының асылын аңлау | | |
| 17 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең берлек санда юклык формасында зат-сан белән төрләнеше | Хәзерге заман хикәя фигыльнең берлек санда юклыкта зат-сан белән төрләндерә белү | | |
| 18 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең күплек санда юклык формасында зат-сан белән төрләнеше | Хәзерге заман хикәя фигыльне күплектә юклык формасында зат-сан белән төрләндерә белү | | |
| 19 | Дистә саннары | Дистә саннарын белү | | |
| 20 | Сәгать ничә? Сәгать ничәдә? | Вакытны әйтә, сорый белү | | |
| 21 | Минем көндәлек режимым | Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйли белү | | |
| 22 | Боерык фигыль формасы | Савыт-сабаларны сөртергә куша белү | | |
| 23 | Исемнең төшем килеше | -ны/-не кушымчасы. Исемнәрне төшем килешенә куя белү | | |
| 24 | Исемнәрнең юнәлеш,урын-вакыт, чыгыш килешендә төрләнүе | Исемнәрне юнәлеш,чыгыш,урын-вакыт килешләрендә төрләндерә белү | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 25 | Нәрсә ашыйбыз, нәрсә эчәбез? | Нәрсә ашаганыңны, нәрсә эчкәнеңне әйтә белү | | |
| 26 | Контроль  эш | Укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү | | |
| 27 | -чы/-че  сүз ясагыч кушымчасы | Әти-әниләрнең кем булып, кайда эшләвен, профессия исемнәрен әйтә белү | | |
| 28 | Мин өйдә булышчы | Табынны ничек әзерләү турында сөйли белү. Эш куша белү | | |
| 29 | Кыш айлары,кыш билгеләре | Кыш айларын атый, билгеләрен әйтә белү | | |
| 30 | Сыйфат сүз төркеме | Сыйфатларны җөмләдән таба белү | | |
| 31 | Кышкы уеннар | Кышкы уеннарны белү һәм алар турында сөйли алу | | |
| 32 | Сыйфатның артыклык, чагыштыру дәрәҗәсе | Предметларның кайсысы зуррак, кечкенәрәк, матуррак икәнен әйтә белү | | |
| 33 | Әдәпле сүзләр | Телефоннан әдәпле сөйләшә белү | | |
| 34 | Контроль эш | Укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү | | |
| 35 | Без җәйне яратабыз | Җәй көне укулар тәмамланганын әйтә белү | | |